**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Зур Сәрдек авыл җирлеге Башлыгы**
**карары**

**12 ноябрь 2020 ел** **№5**

**«Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Зур Сәрдек авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 24 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Зур Сәрдек авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Сәрдек авылы, Үзәк урам, 114 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 24 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Зур Сәрдек авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Сәрдек авылы, Үзәк урам, 114 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2020 елның 24 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Зур Сәрдек авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Сәрдек авылы, Үзәк урам, 114 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. Халык җыенына чыгарылган мәсьәләне расларга:

«Көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 5 һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтәге һәм аннан да өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Зур Сәрдек авылы урамнары юлларын вак таш түшәп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Зур Сәрдек авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Зур Сәрдек авылында урам юл челтәрен карап тоту;

- Зур Сәрдек авылына янгын инвентарьлары алу;

- Зур Сәрдек авылына урам спорт җиһазлары сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Зур Сәрдек авылы чишмәсен төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Зур Сәрдек авылына керү һәм чыгу урыннарында видеокамералар урнаштыру;

- Зур Сәрдек авылы мәдәният йортында җиһазлар сатып алу;

- Зур Сәрдек авылында автомобиль күперен төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге Башлыгы: Ф.М.Фәттахов